ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады хакында

Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына яшьләрнең хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, граждан-патриотик тәрбия чараларына аеруча игътибар биреп, «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп торуны дәвам итүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, җәмгыять тормышыннан аерым булган яшьләргә аеруча игътибар биреп, балаларда һәм яшьләрдә аңлы рәвештә патриотизм булдыруга юнәлдерелгән эшне көчәйтергә.

4.2. Балаларның һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең Татарстан Республикасы региональ бүлеге белән берлектә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү эшен дәвам итәргә.

4.3. Алкогольле эчемлекләр, никотинлы продукция һәм наркотик чаралар куллануны профилактикалауга юнәлдерелгән тематик чаралар уздыру эшен активлаштырырга.

4.4. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары белән берлектә:

4.4.1. яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында, шәһәр округында яшьләр иҗтимагый оешмалары белән хезмәттәшлекне активлаштырырга;

4.4.2. ташландык хәлдә булган һәм максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмый торган балалар савыктыру лагерьлары, мәктәпкәчә белем бирү һәм гомуми белем бирү оешмалары, ял базалары территорияләренә һәм күчемсез милек объектларына комплекслы инвентаризация үткәрергә;

4.4.3. территорияләрендә балалар савыктыру лагерьлары булмаган Татарстан Республикасы муниципаль районнарында яшәүче балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча тәкъдимнәр эшләргә;

4.4.4. авыр тормыш хәлендә һәм социаль куркыныч хәлдә булган балаларны балалар иҗтимагый оешмалары, яшүсмерләр клублары эшчәнлегенә җәлеп итү, аларны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү эшен дәвам итәргә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентына:

5.1. Татарстан Республикасы муниципаль районнарында яшьләр палаталары (парламентлары) системасын үстерү эшен дәвам итәргә.

5.2. Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары каршындагы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре, яшьләр советлары белән хезмәттәшлек практикасын дәвам итәргә.

5.3. Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, милләтара мөнәсәбәтләрне ныгыту, шәхеснең гармонияле үсешенә ярдәм итә торган кыйммәтләр системасын булдыру максатларында яшьләр белән эшне көчәйтергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 8 июне
№ 630-VII ДС